**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Карар

**№ 90** **21 январь 2019 ел**

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгының 2018 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2019 елга фараз турында хисабы

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгының 2018 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2019 елга фараз турында хисабын тыңлап һәм фикер алышып. Депутатлар билгеләп үткәнчә, Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы эшчәнлеге 2018 елда авыл җирлеге халкы мәнфәгатьләрендә, «РФда җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең 6.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Законы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елдагы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән компетенция һәм вәкаләтләр нигезендә гамәлгә ашырылган, Совет Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге:

1. Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгының 2018 елда авыл җирлегенең социаль – икътисадый үсеше нәтиҗәләре һәм 2019 елга фараз турында хисабын игътибарга алырга.
2. 2019 елда авыл җирлеген социаль – икътисади үстерүнең төп бурычы булып халыкның тормыш сыйфаты үсешен тәэмин итү санала.
3. Шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә аерым игътибар бирергә.
4. Халыкның тормыш дәрәҗәсен төшерүгә юл куймау һәм гражданнарның социаль хезмәтләргә тигез керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар күрергә.
5. Хокук саклау органнары белән берлектә җәмәгать иминлеге дәрәҗәсен күтәрү һәм җәмәгать тәртибен, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген һәм дәрәҗәсен ышанычлырак яклауны тәэмин итү буенча алга таба эш алып барырга.
6. Яңа Аксубай авыл җирлеген төзекләндерү, яшелләндерү һәм чистарту, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча чараларны дәвам итәргә.
7. Яңа Аксубай авыл җирлеге башкарма комитетына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне үтәү буенча чаралар планын эшләргә тәкъдим итәргә.
8. Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы аппаратына хисап докладында һәм аны тикшергәндә әйтелгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерергә.
9. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru.
10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яңа Аксубай авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе: М.М.Сулейманкин